**Муниципальное автономное дошкольное образовательное учреждение города Набережные Челны «Детский сад общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по познавательно-речевому направлению развития детей №15 «Кубэлэк»**

**Яр Чаллы шәһәренең "Күбәләк" 15 нче балаларның танып белү-сөйләм үсешен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы" муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе**

423803, Республика Татарстан, г. Набережные Челны, ул. им. ХадиТакташа, д.24 (ЗЯБ 18/71)
Телефон (факс): (8552) 46-59-02
e-mail: sad15.87@mail.ru

ИНН 1650086230/ КПП 165001001
л/с ЛАГ30800007-ДС15/л/с ЛАВ30800008-ДС15
р/с 40603810405020000901 в ПАО «Ак Барс» Банк г. Казань
БИК 049205805 к/с 30101810000000000805

# *"Уеннарда авазлар"*

***фонетик лексик уен – күнегүләр***

***(икенче кечкенәләр төркеме)***

**Әзерләде**
**15 нче "Күбәләк" балалар бакчасының**
**югары категорияле татар теле тәрбиячесе**
**Гумерова Нәкыя Назим кызы**

| | |
|---|---|
| ***Капканы ач!***<br>Балаларярымтүгәрәк ясап утыралар.<br>Тәрбияче сөйли:<br>- Балалар, әйдәгез, тел очын өске тешләргә<br>тидерик һәм телнең алгы өлешен теш казналарына таба хәрәкәт иттерик. “Капканы ач!” дип әйтүгә, кискен итеп сулыш чыгарыйк: т!. *(Балалар биремне үтиләр).*<br>Ә хәзер {т} авазы кергән сүзләр әйтергә өйрәнәбез. Минем арттан кабатлагыз әле: та-та-та; тә-тә-тә; ту-ту-ту! Тот-тот-тот! Эт-т-эт! Ат-ат-ат!<br>***Методик күрсәтмә:***{т} авазын әйткәндә, телнең алгы өлеше өске тешләргә һәм теш казналарына таба хәрәкәт итә. Бу аваз – саф йомык тартык. {т} авазы ясалганда сөйләм органнарының киртә хасил иткәне тулысынча ябыла һәм һава агышы тәһсирендә кисәк кенә ачылып китә. Бу авазны әйткәндә, тавыш ярылары тирбәнмиләр, тавыш катнашмый. Бу аваз – саңгырау тартык. | ***Таганда атыну.***<br>Балаларярымтүгәрәк ясап утыралар.<br>Тәрбияче сөйли:<br>- Балалар, безнең авызда бик тә шаян һәм<br>шул ук тел яши. Телнең бик чыгасы килә, ә абыйлары “тешләр” аны чыгармыйлар. Тел барыбер чыга да таганда атынган шикелле уйный. Әйдәгез, сез дә уйнап карагыз әле! (...) Менә шулаай. Тел агы да катырак атылсын өчен, өрик, балалар, тешләр чыгармаган тел эчтә.: “Д-д-д” дип кычкыра. Кабалыйк әле. (...). Кычкырып җырлый да әле ул: “Дә-дә-дә, ду-ду-ду”. *(Балаларкабатлыйлар).*<br>***Методик күрсәтмә:*** {д} авазын әйткәндә, телнең алгы өлешеөске тешләргә һәм теш казналарына таба хәрәкәт итә. Бу аваз – саф йомык тартык. {д} яңгырау тартыгын әйткәндә, тавыш ярылары тирбәнеп тавыш чыгаралар. |
| ***Тыныш тел***<br>Балаларярымтүгәрәк ясап утыралар.<br>Тәрбияче сөйли:<br>- Балалар, тыныш телнең урамга чыгасы<br>килә. Ә тешләр аны чыгармый. Тыныш тел этеп карый, әмма тешләр һаман ачылмый. Шуннан соң тел бик каты көчәнеп этә, һава авыздан да боыннан да чыга башлый. Шул вакыт тешләр ачылып китә. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: н-н-н, н-н-н, н-н-н. Бик хшы.<br>***Методик күрсәтмә:*** {н} авазын әйткәндә, телнең алгы өлеше өске тешләргә һәм теш казналарына таба хәрәкәт итә. Тавы ярылары тирбәлеп тавыш чыгаралар. Бу аваз – яңгырау тартык. | ***Тишек шар***<br>Балаларярымтүгәрәк ясап утыралар.<br>Тәрбияче шар кабарта, аннан соң шарның тынын әкрен генә чыгара башлый.<br>- Балалар, карагыз әле, шарның тыны ничек<br>сызгырып чыга: с-с-с, с-с-с, с-с-с! Ягез әле, хәзер сез күрсәтегез, шарның тыны ничек чыга? *(Балалар, “с-с-, с-с-с, с-с-с” дип, акрын, уртача, һәм тиз темпта кабатлыйлар.)*<br>***Методик күрсәтмә:*** {с} авазын әйткәндә, телнең алгы өлеше аскы тешләргә һәм теш казналарына таба хәрәкәт итә. Тавышярылары тирбәнмиләр, тавыш катнашмый. Бу аваз – саңгырау тартык. |

| | |
|---|---|
| ***Элмәк***<br>Балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар. Тәрбияче сөйли:<br>- Әйдәгез балалар авызны аз гына ачып,<br>иреннәрне иркен итеп җәябез Телне уңайлы итеп аскы тешләргә тидерәбез. Хәзер шул килеш э-э-э дип әйтик. Э-э-э. Булдырдыгыз. Балалар, безгә кунакка Энҗе килгән. Аның кулында төенчек бар. Төенчеккә элмәк тегелгән. Энҗе элмәкне элгечкә эләктерергә тырыша. “Э-э-элен, элмәк”, - ди. Яле, бергәләп: “Э-э-э, э-э-э, э-э-э”. Хәзер, әйдәгез, Энҗегә булышыйк: “Э-э-элен, э-э-элмәк!” *(Берничә тапкыр кабатлыйлар).* Бик яхшы.<br>***<u>Методик күрсәтмә:</u>*** {э} авазын әйткәндә, иреннәр киң итеп елмаялар, ә тел очы аскы тешләргә тиеп тора. | ***Шартла куык!***<br>Балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар, тирән сулыш алган килеш, иреннәрен кысып ябалар. Шул халәттә 4 – 6 секунд торалар. “Шартла куык!” дигән сигналдан соң, шартлау авазы белән сулыш чыгаралар. Сулышны көчле, утрача, акрын шартлау белән чыгаралар.<br>- Балалар, куык шартлаганда нинди аваз<br>әйтелә? Әйе, {б} авазы. Әйдәгез, бергәләп тагын әйтик әле: б-б-б, б-б-б, б-б-б.<br>Ә хәзер {б} авазына башланган тагын берничә сүз әйтик:<br>Б-б-б, ба-ба-ба- бабай.<br>Б-б-б, бә-бә-бә-бәби.<br>Б-б-б, би-би-би-әби.<br>***<u>Методик күрсәтмә:</u>*** {б} авазын әйткәндә, иреннә бер-берсенә таба хәрәкәт итәләр. Бу аваз – ирен тартыгы. Йомык, чөнки сөйләм органнарының берсе тулысынча йомыла һәм үпкәдән килүче һава агымы тәһсирендә кисәк кенә ачыла. |
| ***Тишек туп***<br>Балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар.<br>- Балалар, әйдәгез, тирән итеп тын алыйк<br>һәм иреннәрне нык итеп ябып куйыйк. “Туп тишелгән!” дигәч, иреннәрне ачып һава чыгара башлыйбыз. *(Уен берничә тапкыр кабатлана)*<br>***<u>Методик күрсәтмә:</u>*** {п} авазын әйткәндә, иреннәр бер-берсенә таба хәрәкәт итәләр. Бу аваз – ирен тартыгы. Йомык, чөнки иреннәр тулысынча йомыла һәм үпкәдән килүче һава агымы тәһсирендә кисәк кенә ачыла. Бу авазны әйткәндә, тавыш ярылары тирбәнешләре тавыш ясауда катнашмый. | ***Авыртамы?***<br>Балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар. Тәрбияче сөйли:<br>- Балалар, Алия – курчак бүген күп эшләгән. Кер юган, идән юган, курчакларның тузаннарын сөрткән. Эшләгәндә бармагын авырттырган. Әрнүе кимесен өчен, бармагына өрә: ф-ф-ф! ф-ф-ф! Бе дә шулай итеп карыйк әле *(тәрбияче өрә, балалар кабатлыйлар).* Барма нык авыртса, тиз-тиз өрергә кирәк. (...) Авырту кимегәч, акрынрак өрергә дә ярый. (...)<br>***<u>Методик күрсәтмә:</u>*** {ф} авазын әйткәндә, аскы ирен кискеч тешләргә таба хәрәкәт итә. Бу ваз – өрелмәле тартык. {Ф} авазын әйткәндә, тавыш ярылары тирбәнмиләр, тавыш катнашмый, шуңа күрә бу аваз – саңгырау тартык. |

### *Ишекне ач һәм яп*

Балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар. Тәрбияче сөйли:

- Миңа телләрегезне күрсәтегез әле. аларның бик тә уйныйсылары килә икән. Әйдәгез әле, бераз уйнатып алыйк аларны. Тел очын өске тешләргә тидерик. Телнең уртасын өскә күтәрик. Аска төшерик.. Менә телләрегез бераз уйнап алды, хәзер инде алар бераз ял итсеннәр.

***Методик күрсәтмә:*** Сөйләм аппараты органнарының кирәкле хәрәкәтләрен һәм торышын билгеләү. Авазларны дөрес әйтергә өйрәнү.

### *Серле тартма*

Карагыз әле, безгә кунакка урманнан аю килгән! Ул үзе белән “Серле тартма” да алып килгән. Юлда килгәндә бик арыган, шуңа күрә утырып ял итсен әле. Аю нәрсә ди: “И-и-и, монда нинди матур балалар!”. Тагын нәрсә дип әйтә икән, тыңлыйк әле: “Ы-ы-ы, мин сезне тыңлыйм, сез миңа һөнәрләрегезне күрсәтегез” – ди. Әйдәгез әле, балалар без дә аю артыннан кабатлыйк: и-и-и. Әйдәгез әле, үзегез генә әйтеп карагыз: и-и-и. Яле, Самир, син иптәшләреңә әйтеп күрсәт әле. (...). Бик яхшы. Балалар әйдәгез әле, аюның икенче авазын да кабатлыйк: ы-ы-ы. Алия, әйдә әле, аюга син әйтеп күрсәт. (...). Бик яхшы. Аю: “Ы-ы-ы, урманга кайтасым килә”, - ди. Әйдәгез аю белән саубуллашыйк.

- Сау бул, аю!

***Методик күрсәтмә:*** Балаларның {ы} авазын татар телендә, иреннәрне киң җәймичә, телне артка таба тартмыйча гына әйтүләренә игътибар итәргә кирәк.

### *Кем күпме түзә?*

- Ягез әле, тирән итеп сулыш алыгыз.

Иреннәрне кысып, сулыш тоткарлагыз. Һәм акрын, уртача, кызу тизлектә сулыш чыгарыгыз (...). Бик яхшы. Балалар, безг Өммия кунакка килгән. Ул бүләккә көзгеләр алып килгән *(көзгеләр тарату)*. Барыбыз да көзгегә матур итеп карыйк. Иреннәрне түгәрәкләндереп алга таба сузыйк, ә тел очын аскы тешләр артына яшерик. “Ө-ө-ө” дип әйтик. Ө-ө-ө. Бик яхшы.

***Методик күрсәтмә:*** {ө} авазын әйткәндә, тел авыз куышлыгының алгы өлешенә килә. Бу аваз иренләшкән, шуңа күрә иреннәр түгәрәкләнеп алга таба сузылалар.

### *Помидор*

- Балалар, безгә Оркыя апа килгән. Исәнме Оркыя апа, әйдә түрдән уз.
- Исәнмесез, балалар. О-о-о, баскыч бигрәк

биек, менә алмыйм. Әгәр минем арттан кабатласагыз, мин бик җиңел менәр идем. *(Балалар Оркыя апа белән бергә кабатлыйлар).*

- Балалар, Оркыя апа безгә помидор алып

Килгән. О-о-о, ул нинди зур, кызыл, түгәрәк. Әгәр Оркыя апа артыннан: “О-о-о, помидор!” дип кабатласак, ул безнең белән уйныйм ди. Әйдәгез әле, әйтеп карыйк *(кабатлау)*. Бик яхшы, балалар. Помидорның зурлыгын куллар белән күрсәтик. О-о-о, ул нинди зур, түгәрәк. *(Куллар белән зур түгәрәк ясау).* Ә хәзер без кечкенә помидор ясыйк. *(Куллар белән кечкенә помидор ясау).*

***Методик күрсәтмә:*** {о} авазы авызны зур ачып, иреннәрне түгәрәкләп әйтелә.

| | |
|---|---|
| ***“Кем оста?”***<br>Балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар. Тәрбияче сөйли.<br>- Балалар, безнең тел авызда бер дә тик Тормый, һәрвакыт хәрәкәттә. Тел өстен, алга, артка, өскә, аска таба йөртик әле. *(Балалар кхрсәтелгән тел хәрәкәтләрен кабатлыйлар)*<br>- Ә хәзер, әйдәгез, иреннәрне хәрәкәтләндерик. Иреннәрне җәябез, җыябыз, алга чыгарабыз, бөрәбез, теш казнасына тидерәбез. *(өске тешләр белән аскы иренне аннан аскы тешләр белән өске иренне каплыйбыз)* Ә хәзер иякне аска тешерик, өскә күтәрик, уңга-сулга йөртик. Авызга һава алып, авыз куышлыгын киңәйтик, авыздан һаваны чыгарып, авыз куышлыгын тарайтыйк. *(Тәрбияче күрсәтә, балалар кабатлыйлар)*<br>***Методик күрсәтмә:*** Мондый күнегүләр балаларның игътибарын сөйләм аппараты органнарына юнәлтү өчен әһәмиятле, аларны башка авазларны өйрәнер алдыннын да үтәргә киңәш ителә. | ***“Курчакларны тынычландыру”***<br>Һәр баланың кулында курчак. Тәрбияче әйтә:<br>- Курчаклар йолый, аларны тынычланды-<br>рырга кирәк. Карагыз әле, мин ничек тирбәтәм. *(Таныш көй белән “а-а-а” дип көйли)* Балалар курчак йолавыннан туктады. Аның йоклыйсы килә. Ниче тирбәтим? *(“Ә-ә-ә” дип көйли).*<br>Балалар, “а-а-а” дип, курчакны тынычландыралар һәм “ә-ә-ә” дип йоклаталар.<br>***Методик күрсәтмә:*** Тәрбияче һәр баланың бу авазларны дөрес әйтүенә игътибар итә, кирәк булганда сөйләм аппараты органнарының дөрес хәрәкәтенә һәм торышына ирешү өчен индивидуаль алымнар куллана. |
| ***Бүре һәм бүре балалары***<br>Балалар япымтүгәрәк ясап утыралар. Тәрбияче аларга бүре һәм бүре балалары рәсемен күрсәтә<br>- Балалар, менә бу рәсемгә карагыз әле. Анда бүре, балалары белән бергә, салкын, караңгы кырда калган. Бүре “У-у-у, у-у-у, у-у-у!” дип улап иптәшләрен чакыра.<br>Иреннәргә карагыз әле: у-у-у дип әйткәндә, алар очлаеп алга сузыла. Әйдәгез, бергәләп әйтик: у-у-у, у-у-у, у-у-у. *(Балалар тәрбияче белән бергә кабатлыйлар.)*<br>- Ә бүренең кечкенә балалары: “Ү-ү-ү, ү-ү ү, ү-ү-ү” – диләр. . Аларга салкын, тавышлары да көчсез: “Ү-ү-ү!”, “ү-ү-ү!” дип әйткәндә, иреннәр тагы да ныграк очлаеп алга таба сузылалар. Әйдәгез әле, без дә бүре балалары кебек әйтеп карыйк: Ү-ү-ү, ү-ү-ү, ү-ү-ү! *(Кабатлыйлар.)*<br>***Методик күрсәтмә:*** Балаларның{у} һәм {ү} авазларын көчәнмичә әйтүенә ирешергә кирәк. | ***Тишек шар***<br>Балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар. Тәрбияче шар кабарта, аннан соң шарның тынын әкрен генә чыгара башлый.<br>- Балалар, карагыз әле, шарның тыны ничек<br>чыга: с-с-с, с-с-с, с-с-с! Ягез әле, хәзер сез күрсәтегез, шарның тыны ничек чыга? *(Балалар, “с-с-с, с-с-с, с-с-с” дип акрын, уртача һәм тиз темпта кабатлыйлар.)*<br>***Методик күрсәтмә:*** {с} авазын әйткәндә, телнең алгы өлеше аскы тешләргә һәм теш казналарына таба хәрәкәт итә. Тавыш ярылары тирбәнмичә, тавыш катнашмый. |